РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

2021 елның 10 феврале 38№

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАРЫ**

**Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 23 августындагы «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 343 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше нәтиҗәләре һәм 2021 елга республикасының финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары турындагы 2021 елның 04 гыйнвары ПР - 1 номерлы карары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсенең 24,25 пунктларын үтәү йөзеннән, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 23 августындагы «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 343 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарның 1 пунктындагы 1 абзацында түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү мәҗбүри».

- карарның 1 пунктындагы 2 абзацында «педагогик хезмәткәрләргә», «мәгариф оешмаларында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ бюджет формалаштырганда район бюджетының өстәмә чыгымнарын каплау чыганакларын билгеләргә.

3. Муниципаль белем бирү учреждениеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре җитәкчеләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын алу мөмкинлеге турында тиешле аңлату эшләре алып барырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов